ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. Чит ил гражданнары, әлеге Кодексның 4 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, гражданлыгы булмаган затлар, чит ил оешмалары, халыкара оешмалар һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләр, чит ил агентлары кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүгә, теркәлгән кандидатларны сайлауга, сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә ярдәм итә йә комачау итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга, шулай ук башка рәвешләрдә сайлау кампанияләрендә катнашырга хокуксыз.»;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфасына кандидат итеп Россия Федерациясендә даими яшәүче, пассив сайлау хокукына ия булган, тавыш бирү көненә 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы күрсәтелергә мөмкин.»;

3) 10 статьяның $13^{1}$ өлешендәге беренче абзацында «инвалидларның федераль реестры белешмәләре» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

4) 16 статьяның $6^{1-1}$ өлешендә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 27 статьяның 4 өлешендәге өченче җөмләсендә «сайлау комиссияләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау участоклары территориясендә сак астында тоту урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектының сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 31 статьяның 2 өлешендә «дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарылырга тиеш, шулай ук ул» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 61 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $3^{1}$ өлеш өстәргә:

«$3^{1}$. Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны бер үк вакытта бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары һәм бердәм сайлау округы буенча үткәргәндә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, тиешенчә региональ (республика) дәүләт яисә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган эфир вакытының гомуми күләменең икедән бере – сайлау алды агитациясен алып бару өчен тигез өлешләрдә теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре арасында, калган өлеше сайлау алды агитациясен алып бару өчен тигез өлешләрдә бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча күрсәтелгән барлык теркәлгән кандидатлар арасында бүленә.»;

б) 6 өлештә «муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары» сүзләреннән соң «тигез өлешләрдә» сүзләрен өстәргә;

8) 62 статьяда:

а) $1^{1}$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны бер үк вакытта бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары һәм бердәм сайлау округы буенча үткәргәндә тиешенчә региональ (республика) дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган матбугат мәйданының гомуми күләменең икедән бере – сайлау алды агитациясен алып бару өчен теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренә, калган өлеше сайлау алды агитациясен алып бару өчен бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча күрсәтелгән теркәлгән кандидатларга бүлеп бирелә.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау алды агитациясен алып бару өчен вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан әлеге статьяның $1^1$ өлеше нигезендә бирелә торган түләүсез матбугат мәйданының гомуми күләме теркәлгән кандидатлар, теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре арасында шушы күләмне бу вакытлы матбугат басмасында түләүсез матбугат мәйданы алуга хокукы булган теркәлгән кандидатлар, теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре санына бүлү юлы белән бүленә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 апрель
№ 31-ТРЗ